СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**2019 ел, «14» март** **№ 228**

**2011 елның 17 февралендәге 35-1 нче номерлы Арча район Советы карары (2014 елның 13 декабрендәге 306 нчы номерлы, 2017 елның 24 мартындагы 115 нче номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган « Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең әхлак һәм хезмәт тәртибе Кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Арча район Советы карар чыгарды:

1. 2011 елның 17 февралендәге 35-1 нче номерлы Арча район Советы карары (2014 елның 13 декабрендәге 306 нчы номерлы, 2017 елның 24 мартындагы 115 нче номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең әхлак һәм хезмәт тәртибе Кодексына үзгәрешләр кертергә һәм кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г.Нуриев

Кушымта
Арча район Советының
2019 елның «__» ________
____ номерлы Карарына

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең әхлак һәм хезмәт тәртибе Кодексы**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең әхлак һәм хезмәт тәртибе Кодексы (алга таба – Кодекс) Россия Федерациясе Конституциясе, «Муниципаль хезмәт турында» Модель закон (Парламентара дәүләтләр Ассамблеясының – Бәйсез Дәүләтләр Берлеге дәүләтләренең (2002 елның 26 мартындагы 19-10 нчы номерлы карары) 19 нчы пленар утырышында кабул ителде), 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Ришвәтчелеккә каршы тору турында», 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» федераль законнары, муниципаль хезмәткәрләр өчен чикләүләр, тыюлар һәм бурычларны билгеләүче башка федераль законнар, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларга нигезләнеп, Россия җәмгыятенең һәм дәүләтнең әхлакый принципларын һәм нормаларын исәпкә алып эшләнде.

2. Кодекс Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре (алга таба – муниципаль хезмәткәрләр), башкарган вазыйфаларына бәйсез рәвештә үтәргә тиеш булган төп әхлак һәм хезмәт кагыйдәләренең гомуми принциплары җыентыгы булып тора.

4. Муниципаль хезмәткә урнашучы Россия Федерациясе гражданы Кодекс нигезләмәләре белән танышырга һәм хезмәт вазыйфаларын башкару дәверендә, шул исәптән Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрен кулланган вакытта, аларны төгәл үтәргә тиеш.

5. Һәр муниципаль хезмәткәр Кодекс нигезләмәләрен үтәү өчен барлык кирәкле чараларны күрергә тиеш, Россия Федерациясенең һәр гражданы муниципаль хезмәткәрдән аның белән Кодекс нигезләмәләренә нигезләнгән мөнәсәбәт көтәргә хокуклы.

6. Кодексның максаты – хезмәт вазыйфаларын тиешле дәрәҗәдә башкаруны тәэмин итү максатында муниципаль хезмәткәрләр өчен әхлак нормаларын һәм хезмәт кагыйдәләрен билгеләү, муниципаль хезмәткәләрнең дәрәҗәсен күтәрү, гражданнарның җирле үзидарә органнарына ышанычын ныгыту һәм муниципаль хезмәткәрләрнең бердәм хезмәт кагыйдәләрен булдыру.

7. Кодекс муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларын башкару нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән.

8. Кодекс муниципаль хезмәт өлкәсендә тиешле әхлак кагыйдәләрен, җәмәгатьчелектә муниципаль хезмәткә карата ихтирамлы мөнәсәбәт формалаштыру өчен нигез булып тора, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең иҗтимагый аң һәм әхлак, аларның үз-үзен контрольдә тоту институты булып тора.

9. Муниципаль хезмәткәрләрнең Кодекс нигезләмәләрен белүе, аларның үтәлешен тәэмин итү муниципаль хезмәткәрләрнең профессиональ эшчәнлеген һәм хезмәт кагыйдәләрен үтәү сыйфатын бәяләү критерийларының берсе булып тора.

## II. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәттә үз-үзләрен тоту тәртибенең төп принциплары һәм кагыйдәләре

10. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәттә үз-үзләрен тоту тәртибенең төп принциплары муниципаль хезмәт башкару белән бәйле рәвештә Россия Федерациясе гражданнарына үз-үзләрен тоту өчен нигез булып тора.

11. Муниципаль хезмәткәрләр, дәүләт, җәмгыять һәм гражданнар алдында җаваплылык тоеп,

а) җирле үзидарә органнарының нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин итү максатында вазыйфаи бурычларын намуслы итеп һәм югары профессиональ дәрәҗәдә башкарырга;

б) кеше һәм гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм саклау җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең төп асылын тәшкил итүен истә тотып эш итәргә;

в) эшчәнлекне тиешле җирле үзидарә органы вәкаләтләре чигеннән чыкмыйча башкарырга;

г) төрле профессиональ яки социаль төркемнәргә һәм оешмаларга өстенлек бирмәскә, аерым гражданнар, профессиональ яки социаль төркемнәр яки оешмалар йогынтысына бирелмәскә;

д) вазыйфаи бурычларны намуслы итеп башкаруга комачаулаучы шәхси, милек (финанс) яки башка мәнфәгатьләр йогынтысына бирелмәскә;

е) муниципаль хезмәткәр эш бирүче, прокуратура органнары һәм башка органнар яки җирле үзидарә органнары вәкилләренә ришвәтчелек белән бәйле хокук бозуга этәрүче мөрәҗәгатьләр керү турында хәбәр итәргә;

ж) федераль законнар белән билгеләнгән чикләү һәм тыюларны, муниципаль хезмәт башкару белән бәйле бурычларны үтәргә;

з) сәяси партияләр һәм җәмәгать берләшмәләре карарларының хезмәт эшчәнлегенә йогынты ясавын булдырмыйча гаделлек сакларга;

и) хезмәт, профессиональ әхлак нормаларын һәм үз-үзеңне эшлекле тоту кагыйдәләрен үтәргә;

к) гражданнар һәм вазыйфаи затлар белән аралашканда әдәплелек һәм игътибарлык күрсәтергә;

д) Россия һәм башка дәүләт халыклары гореф-гадәтләренә түземлелек һәм хөрмәт күрсәтергә, төрле этник, социаль төркемнәр һәм конфессияләрнең мәдәни һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алырга, милләтара һәм конфессияара килешүне тәэмин итәргә;

м) муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларын намуслы башкаруында шик тудырырга мөмкин булган адымнардан тыелып торырга, шулай ук аның абруена яки җирле үзидарә органы дәрәҗәсенә зыян китерергә мөмкин булган каршылыклы хәлләрне булдырмаска,

н) мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм барлыкка килгән мәнфәгатьләр каршылыгы очракларын җайга салу буенча Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән каралган чаралар күрергә;

о) шәхси мәсьәләләрне хәл иткәндә җирле үзидарә органнары, оешмалар, вазыйфаи затлар, муниципаль хезмәткәрләр һәм гражданнар эшчәнлегенә йогынты ясау өчен хезмәт урыныннан файдаланмаска;

п) муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларына кермәгән очракта җирле үзидарә органы, аның җитәкчесе эшчәнлегенә карата ачык фикер белдерүдән, бәя бирүдән тыелып торырга;

р) җирле үзидарә органында каралган ачык чыгышлар һәм хезмәт мәгълүматын бирү кагыйдәләрен үтәргә;

с) җирле үзидарә органы эшчәнлеге турында халыкка җиткереп баручы массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре эшенә хөрмәт белән карарга, каралган тәртип буенча дөрес мәгълүмат биүне тәэмин итәргә;

т) ачык чыгышларда, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында, Россия Федерациясе территориясендә товарларны, эш башкаруны хезмәт күрсәтүне һәм башка төр гражданлык хокуклары объектларын, Россия Федерациясе резидентлары арасында килешү суммаларын, Россия Федерациясенең барлык дәрәҗәдәге бюджет системасында бюджет күрсәткечләрен, дәүләт һәм муниципаль бурыч алу, дәүләт һәм муниципаль бурыч күләмнәрен, төгәл мәгълүмат бирү яки Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары белән, Россия Федерациясе халыкара килешүләре белән каралган һәм эшлекле әйләнеш өчен кирәк булган очраклардан тыш, чит ил валютасында (шартлы акча берәмлегендә) бәяләүдән тыелырга;

у) һәрдаим аның җаваплылыгында булган ресурслар белән нәтиҗәле идарә итүне тәэмин итүгә омтылырга тиеш.

12. Муниципаль хезмәткәрләр Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының башка хокукый актларын, муниципаль хокукый актларны үтәргә тиеш.

13. Муниципаль хезмәткәрләр үз эшчәнлекләрендә сәяси, икътисадый максаттан яки башка мотивлардан чыгып, законнарны һәм башка норматив хокукый актларны бозмаска тиеш.

## III. Муниципаль хезмәткәрләрнең ришвәтчелеккә каршы тору кагыйдәләре стандарты

14. Муниципаль хезмәткәрләр ришвәтчелек күренешләрен булдырмаска һәм аны булдырмау өчен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган чаралар күрергә тиеш.

15. Муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаи бурычларын башкарган вакытта мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләргә юл куймаска тиеш. Муниципаль хезмәткә билгеләнгән вакытта һәм вазыйфаи бурычларны башкарганда муниципаль хезмәткәр вазыйфаи бурычларны башкаруга йогынты ясаучы яки йогынты ясарга мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләре турында белдерергә тиеш.

16. Муниципаль хезмәткәр үзе, гаилә әгъзалары, үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәгълүмат бирергә тиеш.

17. Муниципаль хезмәткәр эш бирүче, Россия Федерациясе прокуратурасы органнары һәм башка органнар вәкилләренә ришвәтчелек белән бәйле хокук бозуга этәрүче мөрәҗәгатьләр керү турында хәбәр итәргә тиеш.

Ришвәтчелек белән бәйле хокук бозуга этәрүче мөрәҗәгатьләр турында хәбәр итү, бу фактлар буенча тикшерү үткәрелгән булмаса яки үткәрелмәсә, муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычы булып тора.

18. Муниципаль хезмәткәргә вазыйфаи бурычларын башкару белән бәйле рәвештә физик һәм юридик затлардан бүләкләр (акчалата, ссуда, матди характердагы хезмәтләр, күңел ачу, ял итү, транспорт белән файдалану өчен түләү һәм башка төр бүләкләр) алу тыела. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан беркетмә чаралары, эш сәфәре һәм башка төр рәсми чаралар белән бәйле рәвештә алынган бүләкләр җирле үзидарә органы милке булып санала һәм, Россия Федерациясе законнары белән каралган очраклардан тыш, акт буенча муниципаль хезмәткәр тарафыннан ул муниципаль хезмәт башкарган җирле үзидарә органына тапшырыла. Беркетмә чаралары, эш сәфәре яки башка төр рәсми чаралар белән бәйле рәвештә бүләк алып, аны җирле үзидарә органына тапшырган муниципаль хезмәткәр ул бүләкне Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән каралган тәртиптә сатып алырга мөмкин.

19. Җирле үзидарә органында Россия Федерациясе законнарына таянып кабул ителгән норма һәм таләпләрне үтәгән вакытта муниципаль хезмәткәр хезмәт мәгълүматын эшкәртергә һәм башкаларга җиткерергә мөмкин.

20. Муниципаль хезмәткәр вазыйфаи бурычларын үтәү дәверендә аңа билгеле булган мәгълүматны яки рөхсәтсез башкаларга тараткан өчен җаваплылык каралган очракларда мондый мәгълүматның сер булып калуын тәэмин итәргә тиеш.

21. Җитәкче урынын биләүче муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәткәрләрне сәяси партияләр, башка иҗтимагый һәм дини берләшмәләр эшчәнлегенә мәҗбүри тарту очракларын булдырмаска тиеш.

22. Башка муниципаль хезмәткәрләргә карата оештыру-боеру вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәр алар өчен профессиональлек, абруй үрнәге булырга, җирле үзидарә органында яки аның бүлекчәсендә нәтиҗәле эшчәнлек булдыру максатында әхлакый-психологик климат тудыруга этәргеч ясарга тиеш.

23. Башка муниципаль хезмәткәрләргә карата оештыру-боеру вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәр:

а) мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм андый очракларны җайга салу буенча чаралар күрергә;

б) ришвәтчелекне булдырмау буенча чаралар күрергә;

в) муниципаль хезмәткәрләрне сәяси партияләр, иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә мәҗбүри тарту очракларын булдырмаска тиеш.

23. Башка муниципаль хезмәткәрләргә карата оештыру-боеру вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәр аңа буйсынучы муниципаль хезмәткәрләр ришвәтчелек очракларын булдырмавын, шәхси тәртипләре белән намуслылык, гаделлек үрнәге күрсәтүен тәэмин итәргә тиеш.

24. Башка муниципаль хезмәткәрләргә карата оештыру-боеру вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәр аңа буйсынган хезмәткәрләр әхлак һәм хезмәт кагыйдәләре принципларын бозса яки аларны игътибарсыз калдырса, ул аларны булдырмый калу өчен чаралар күрмәгән яки игътибарга алмаган очракларда Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

## IV. Муниципаль хезмәткәрләр өчен әхлак һәм хезмәт тәртибе тәкъдимнәре

*25. Хезмәт вазыйфаларын башкарганда муниципаль хезмәткәргә кеше,* аның хокуклары һәм ирекләре – иң зур хәзинә, һәр граждан шәхси тормышның кагылгысызлыгына, шәхси һәм гаилә серенә, намусын, абруен саклауга хокуклы, дигән Конституция нигезләмәләреннән чыгып эш итәргә тиеш.

26. Хезмәт вазыйфаларын башкарганда муниципаль хезмәткәр:

а) җенесенә, ничә яшьтә, нинди расадан һәм милләттән булуына, теленә, гражданлыгына, социаль, мөлкәти һәм гаилә хәленә, сәяси карашларына, дингә мөнәсәбәтенә карамастан дискриминацион характердагы гамәлләрдән һәм сүзләрдән;

б) тупаслык, дорфалык күрсәтүдән, нигезсез, нахак гаепләүләрдән һәм

бәйләнүләрдән,

в) янаулардан, куркытулардан, нормаль аралашуга каршылык тудыручы яки хокук боза торган гамәлләр кылуга этәргеч ясаучы репликалардан һәм гамәлләрдән;

г) хезмәт киңәшмәләре, гражданнар белән әңгәмәләр вакытында тәмәке тартудан;

д) тирә-юньдәгеләр тарафыннан ришвәт алырга ризалык белдерү яки ришвәт сорау итеп кабул ителергә мөмкин булган төрле сүзләрдән, гамәлләрдән, ишарәләрдән тыелырга тиеш.

27. Хезмәт тәртибе белән муниципаль хезмәткәрләр коллективта эшлекле мөнәсәбәт һәм бер-берең белән нәтиҗәле хезмәттәшлек булдыруны тәэмин итәргә тиеш.

Муниципаль хезмәткәрләр әдәпле, игътибарлы, игелекле булырга һәм гражданнар һәм коллегалары белән аралашканда сабырлык үрнәге күрсәтергә тиеш.

28. Вазыйфаи бурычларын башкарган вакытта муниципаль хезмәткәрнең тышкы кыяфәте, хезмәт шартлары һәм эш чаралары форматыннын чыгып, гражданнарда җирле үзидарә органнарына карата хөрмәт хисе тудырырга, рәсмилек, тыйнаклык, чисталык белән аерылып торган гомумкабул ителгән эш стиленә туры килергә тиеш.

Тышкы кыяфәт формалаштыруда район җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре өчен төп кагыйдә булып эшлекле стиль тора. Төп элемет – эшлекле костюм.

## V. Кодекс нигезләмәләрен бозган өчен җаваплылык

29. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан Кодекс нигезләмәләрен бозу очраклары хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия утырышында карала, ә федераль һәм республика законнары белән каралган очракларда Кодекс нигезләмәләрен бозган өчен муниципаль хезмәткәргә карата юридик җаваплылык чаралары күрелә.

Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Кодекс нигезләмәләрен үтәү аттестация вакытында, югарырак вазыйфаларга билгеләү өчен кадрлар резервы төзегәндә, дисциплинар шелтә белдергәндә исәпкә алына.